ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 29 статьясына һәм «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 11 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 29 статьясындагы 3 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 17 (I өлеш), № 24 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 81 (I өлеш), № 92 (I өлеш), № 95 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш), № 47 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) «әлеге Законга 2 нче кушымтада бирелгән рәвештә» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Хәбәрнамә әлеге Законга 2 нче кушымтада бирелгән рәвештә кәгазьдә яисә Татарстан Республикасы электрон документ әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы аша җибәрелә.

Хәбәрнамәгә муниципаль вазыйфаны биләүче һәм үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы зат идарә итүдә түләүсез нигездә катнашырга җыена торган коммерцияле булмаган оешма уставының күчермәсе һәм коммерцияле булмаган оешманың идарә органы турында нигезләмәнең күчермәсе (мондый нигезләмә булган очракта) кушып бирелә.».

**2 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 3 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (II өлеш); 2010, № 1 – 2, № 4 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 11 (I өлеш); 2016, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 57 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 47 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) «әлеге Законга кушымтада бирелгән рәвештә» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Хәбәрнамә әлеге Законга кушымтада бирелгән рәвештә кәгазьдә яисә Татарстан Республикасы электрон документ әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы аша җибәрелә.

Хәбәрнамәгә Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат идарә итүдә түләүсез нигездә катнашырга җыена торган коммерцияле булмаган оешма уставының күчермәсе һәм коммерцияле булмаган оешманың идарә органы турында нигезләмәнең күчермәсе (мондый нигезләмә булган очракта) кушып бирелә.».

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 26 июль
№ 57-ТРЗ